Каюм Насыйрида кунакта

Кече Шырдан – урамнарын, тыкрыкларын элек заманнардан бирле үзгәртмичә саклап калган борынгы авылларның берсе. 1902 елда Каюм Насыйри авылда мәчет салдырган. Совет чорында, манарасы киселгәч, 1972 елга кадәр ул мәктәп булып хезмәт итә. Соңрак бинаны күчергәч, анда китапханә, медицина пункты урнаша. Бу бинаны саклап калу максатыннан, 2013 елда шырданлылар аны кабат мәчет итеп торгызырга карар кылалар.

5 БИТ

Люция Галләмова: «Бөтен барлыгым белән театрда»

«Быел 60 яшьлек юбилеем әзерләнеп беткән иде. Тынычлап көтеп йөрим. Кадрлар бүлегеннән Тимернең вафатын әйтеп шалтыраткач, үземә дә чак кына инфаркт булмады. Режиссерым Рәшит Заһидуллин: «Борчылма, Люция, спектакльне алмаштырмыйбыз. Ролеңуңышлы, спектакльгә Илгизәр Хәсәновны кертәбез», – диде».

7 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 21.02.2017 | №18 (5780)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ТЕЛЛӘР БЕЛГӘН – ИЛЛӘР ГИЗГӘН

Милләте буенча Елена – рус кызы. Гаиләсендә татарлар бөтенләй юк. Ләкин кыз кечкенәдән татар телен үз иткән. IX сыйныфта үзлегеннән татар телен өйрәнә башлаган. Беренче әсәре – Рабит Батулланың «Сөембикә кыйссасы». Елена Сорокина инде сигезенче ел Казан шәһәренең 40нчы гимназиясендә татар теле һәм әдәбияты укыта.

Эльвира МОЗАФФАР

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

1999 елның ноябрендә ЮНЕСКО туган телгә игътибар бирүне күтәреп чыга. Шуннан соң дөньяда, телләрнең әһәмиятен күрсәтү һәм ана теленә сак караш тәрбияләү максатыннан, 21 февраль – Халыкара туган тел көне буларак билгеләп үтелә башлый.

– Телләр белгән – илләр гизгән, ди халык мәкале. Телләр өйрәнү дөньяга карашны киңәйтә, яңа дуслар табарга булыша. Мәктәптә укыган чакта ук татар кызлары белән аралашып үстем. Бергәләшеп татар җырларын тыңлый, татар спектакльләренә йөри идек. Остазларым да яхшы кешеләр иде, аларның да тәэсире булгандыр, – дип сөйли ул.

Мәктәптә укыган чакта ук кыз татар теленнән төрле олимпиадаларда катнаша, татар әдипләренең әсәрләрен укый, аңламаган сүзләрне сүзлектән табып өйрәнә. Кызларының татар теленә тартылуына әти-әнисе башта гаҗәпләнеп караса, соңрак хуплыйлар. Елена Казан дәүләт федераль университетының татар филологиясе һәм тарих факультетында көндезге бүлектә белем ала. Татар телен ныграк үзләштергән саен, үзе өчен яңалык ача бара. Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары, мәдәнияте, тел үзенчәлекләре кызыксындыра аны.

Тел өйрәнүдә ул үзенчәлекле алымнар кулланырга тырыша. Кайчандыр үзе дә үҗәтләнеп татар телен өйрәнгәнгә, балалар белән уртак телне тиз таба. Татар телен өйрәнүче рус балаларының да психологияләрен аңлап эш итә.

– Рус телле балалар өчен аралашу технологиясенә нигезләнгән дәресләр кулайрак дип саныйм, татар телен укытканда, грамматиканы да, башкасын да кызыклы, укучы өчен мавыктыргыч итеп бирү мөһим. Балалар арасында татар теленә караш төрле. Минемчә, телләргә мөнәсәбәт сабыйда балачактан ук формалаша. Бу мәсьәләдә әти-әнинең, укытучыларның да роле зур. Шуңа да без балаларыбызны кечкенәдән толерантлыкка өйрәтергә тиеш. Һәрберебез өчен Туган тел көне тынычлык, дуслык, бердәмлек бәйрәме булсын! – ди Елена Сорокина.

Безнекеләр Абу-Даби күргәзмәсендә

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов эшлекле сәфәр белән Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Абу-Даби шәһәрендә булды. Анда ул IDEX-2017 халыкара оборона күргәзмәсе эшендә катнашты, дип яза «Татар-информ».

Күргәзмәне ачу тантанасы башланыр алдыннан Татарстан Президенты Абу-Даби Әмирлеге Шаһзадәсе, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Кораллы Көчләре югары башкомандующее Мөхәммәд бен Зәед Әль Нахайян һәм ил хакимиятенең башка вәкилләре һәм халыкара күргәзмә кунаклары белән очрашты.

IDEX – Абу-Дабида ике елга бер үткәрелеп килә торган кораллану һәм хәрби техника күргәзмәсе. Кораллану буенча дөньяда иң күренекле күргәзмә 1993 елдан үткәрелә. Татарстан предприятиеләре IDEX күргәзмәсендә 1995 елдан катнашып килә. Анда Яшел Үзән суднолар төзелеше заводы суднолары, Казан вертолет заводы очкычлары, «КАМАЗ» автомобильләре, шулай ук һава һәм диңгез суднолары өчен радионавигация җайланмалары, сугыш кораллары, оптик җайланмалар һәм башка хәрби билгеләнештәге эшләнмәләр куелган. Рөстәм Миңнеханов MAN, IVECO маркалы һәм башка мәгълүм җитештерүчеләрнең броньланган автомобильләре белән кызыксынды, алар – «КАМАЗ» базасында Татарстанда җитештерелә торган шундый ук техниканың төп көндәшләре.

Күргәзмә белән танышканнан соң Татарстан делегациясе Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең милли иминлек мәсьәләләре буенча киңәшчесе Тахнун бен Зәед Әль Нахайян һәм «Tawazun» компаниясе генераль директоры Сәйф Мөхәммәд Әль-Хаҗәри белән эшлекле очрашу уздырды. Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең иң эре компанияләренең һәм күргәзмәне төп оештыручыларның берсе булган «Tawazun» югары технологияләр үсешенә инвестицияләр кертү белән шөгыльләнә. Очрашуда Рөстәм Миңнеханов республиканың икътисади һәм сәнәгать потенциалы турында сөйләде.

tatarstan.ru

УРАМ СӘҮДӘСЕ

Чатырларның тарихка күченгән чагы

Казанның Яңа Савин районында Адоратский белән Лаврентьев урамнары чатындагы базар комплексы төзелеше тәмамланганнан соң андагы сәүдә вагоннары һәм чатырлары бетереләчәк.

Казанда әле хәзер дә төрле урыннарга урнаштырылган 800 киоскны аласы бар.

Автор фотоархивыннан

– Казанда стационар, ягъни капиталь корылма булмаган киосклар өчен 883 урын билгеләнде. Алар азык-төлек, җимеш сулары, автомобиль кирәк-яраклары, нәшрият продукциясе сату, аяк киеме төзәтү кебек юнәлешләрдә эшчәнлек алып барачак. Кулланучылар базары комитеты 539 урынга аукцион-сатуны апрель аенда үткәрергә планлаштыра, – дип хәбәр итте шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Иван Кузнецов мэриядә узган киңәшмәдә.

Аренда биш елга бирелә. Түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенә карап үзгәрә. Казанның тарихи үзәгендә урнашачак киоск урыннары, әлбәттә инде, кыйбатрак булачак. Иван Кузнецов сөйләгәнчә, 2015 елның мартына кадәр дә аренда килешүләре гамәлдә булган эшкуарлар 344 урынга ташламалы рәвештә мөрәҗәгать итә ала.

– Россия Федерациясе Җир кодексына кертелгән төзәтмәләр нигезендә, 2015 елның 1 мартыннан дәүләт һәм муниципаль милекне арендалаучыларга яңа срокка аренда килешүе төзегәндә, ташламалар бирелгән иде. Мэр Илсур Метшин башлангычында, аукцион-сатуда катнашмыйча да, арендалау мөмкинлеге бирә торган документ проекты әзерләнде. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты документны раслап карар кабул итте. Өстенлектән 2015 елның 1 мартына аренда килешүләре гамәлдә булган эшкуарлар файдалана. Аларның сәүдә киосклары таләпләргә җавап бирергә һәм аренда өчен түләү бурычлары булмаска тиеш, – диде Иван Кузнецов.

Казан мэры Илсур Метшин, киоскларга кагылышлы фикерләре белән уртаклашканда, Түбән Кама шәһәрен җитәкләгән чакларын үк искә төшерде.

– Түбән Каманы төзек сыйфатта күрәсе килә бит. Архитекторлар, рәссамнар киосклар проектлары тәкъдим итте. Рәсемдә барысы да бик матур, ә чынбарлыктагы киосклар нигәдер төссез, – диде Илсур Метшин. – Казанда заманында киосклар саны 3 меңгә якынлашты. Шәһәр мондый «ботка» эчендә үсә алмый иде. Урам сәүдәсендә тәртип салуны сорап, казанлылардан да мөрәҗәгатьләр керде. Казанда әле хәзер дә төрле урыннарга урнаштырылган 800 киоскны аласы бар. Башкалада футбол буенча Конфедерация кубогы, Дөнья чемпионаты узачак. Халыкара спорт чаралары-на теләсә кая урнашкан киосклар белән килә алмыйбыз.

Башкала мэры киосларның нәкъ проекттагы кебек булырга тиешлеген катгый кисәтте.

– Проекттагы төсләргә кадәр саклансын. Соңыннан андый буяу юк, дигән акланулар булмасын, – диде Илсур Метшин. – Казанның югары дәрәҗәсенә лаек булырлык, башкала районнары һәм урамнары архитектурасына яраклашырлык киосклар ясалсын.

Шәһәр башкарма комитеты стационар булмаган сәүдә киосклары проектларының берничә вариантын раслаган. Күңеләнә ошаган киоскка заказ гына бирәсе кала. Әгәр эшкуар: «Үзем гаҗәеп матур киоск ясыйм», – дип әйтә икән, аңа мондый хокук бирелә. Ләкин эшкуар үзенең иҗат проектын шәһәрнең баш архитекторы белән килештерергә тиеш.

«Шәһри Казан» газетасында инде хәбәр иткәнебезчә, киләсе җәйдә Казанның 30 паркына һәм скверына да 127 вакытлы сәүдә ноктасы урнаштырыла. Әлеге киоскларда, чатырларда һәм арбаларда пешкән ризыклар, туңдырмалар, сувенирлар сатылачак, фото хезмәте күрсәтеләчәк. Сәүдә урыннары, аукционнар турындагы мәгълүматлар белән Казан муниципаль берәмлеге рәсми сайтының (kzn.ru) Кулланучылар базары комитеты битендә танышып барырга мөмкин.

Дамир БӘДРИЕВ.

Иң арзанлы коймак – Казанда

Казанда Май чабу бәйрәме 25 февраль көнне «Әкият» курчак театры янындагы мәйданда узачак. Май чабу ул – славяннарда кышны озатып, язны каршылау бәйрәме. Әлеге бәйрәм бик борынгыдан, мәҗүсилек чорыннан килә, ягъни аны славяннар православие дине кабул ителгәнче үк билгеләп үткәннәр.

Ул табигать көчләренә, ел вакытларына табыну, аларның күңелен күрергә тырышу белән бәйле булган. Май чабу йоласы карачкы яндыру белән тәмамлана. Ә бәйрәмнең төп атрибуты – кояш символы булган түгәрәк коймак. «Российская газета» язганча, Россиядә Май чабу бәйрәмендә иң арзанлы коймаклар әзерләүче төбәкләр исемлегенә Татарстан, Рязань һәм Оренбург кергән, дип хәбәр итә «Татар-информ». Бәйрәм табынын бәяләр өчен агропортал экспертлары 30 коймаклык продуктлар: 1 литр сөт, ике күкәй, 400 грамм бодай оны, 40 миллилитр көнбагыш мае, ике аш кашыгы шикәр комы һәм тәмәнчә тоз бәясен исәпләп чыгарган. Әлеге иң арзан җыелма Татарстанда 68 сум 23 тиенгә чыккан. Узган ел республика шундый рейтингта дүртенче урыны яулаган булган, һәм бер ел эчендә коймаклар, бәяләр кыйммәтләнү сәбәпле, 1 сум да 32 тиенгә арткан.

Үз сүзеңне әйтергә курыкма

ХАЛЫК ФИКЕРЕ

2013 елдан башлап, Россиядә социаль өлкәдә (мәдәният, социаль тармак, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм спорт) хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәйсез бәяләү буенча зур эш башланган иде.

Иҗтимагый советлар шөгыльләнә әлеге эш белән. Алар бәйсез операторлар ярдәме белән җыелган мәгълүматларны тикшереп, үзләренең карарларын чыгара. Мәсәлән, Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Юлия Абдреева китергән мәгълүматларга караганда, әлеге министрлык каршындагы Иҗтимагый совет әгъзалары арасында инвалидлар, ветераннар, күп балалы гаиләләр дә бар. 2015-2016 елларда республиканың социаль хезмәт күрсәтүче 103 оешмасы тикшерелгән.

– Бәйсез бәяләү нәтиҗәләре безгә тагын да игътибарлырак булырга ярдәм итә. Һәм, әлбәттә инде, алга таба ачыкланган проблемаларны хәл итү юлларын эзлибез. Мәсәлән, әлеге күрсәткечләр нәтиҗәсендә социаль хезмәт күрсәтү оешмалары капиталь төзекләндерелде, җиһазлар алынды, җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең, шул исәптән медицина хезмәткәрләренең һәм аш-су осталарының белемнәре күтәрелде. Хәтта кабул ителгән шикаятьләр тикшерелгәннән соң, Алабуга һәм Апас районнарындагы халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрен ябарга мәҗбүр булдык, – диде Юлия Абдреева.

Хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәйсез бәяләгән вакытта, белгечләр теге яки бу социаль өлкәдәге оешманың эшчәнлеге турында ачык мәгълүмат булуына, күрсәтелгән хезмәтләрнең уңайлы һәм һәр кешегә дә барып ирешелгәнлегенә, хезмәт күрсәтүнең ни дәрәҗәдә тиз башкарылуына, күрсәтелгән хезмәттән канәгать калу-калмавына игътибар итә. Шулай ук хезмәт күрсәтүченең мөлаемлылыгы, игътибарлы булуы да бәяләнә.

Һәр оешма, ким дигәндә, өч елга бер тапкыр әлеге тикшерү аша уза. Ә менә Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый оешма рәисе Чыңгыз Мәхмүтов әйтүенчә, кайбер шәхси медицина учреждениеләре бәйсез белгечләрне үзләренә кертергә теләми икән.

– Дөрес, монда аларны гына да гаепләп булмый. Әлеге система чагыштырмача яңа, шуңа күрә камилләшер урыннары бар. Мәсәлән, пациентлары психик авырулар булган медоешмалар турында ничек мәгълүмат тупларга? Алар бит инде дөрес бәя бирмәячәк. Шулай ук кайбер шәхси оешмалар белән беррәттән, гади халык та анкета рәвешендәге сораштыруларга сагаеп карый, – ди Чыңгыз Мәхмүтов.

Алга таба шушы нәтиҗәләрне искә алып, медицина оешмаларының рейтингы төзелә. «Һәр дәүләт оешмасы рейтингтагы алдынгы урыннар өчен көрәшергә тиеш», – дип саный Чыңгыз әфәнде. Бу исемлек белән Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайтында танышырга мөмкин.

Әлеге сораштыруларда һәркем катнаша ала. Моның өчен министрлыкларның сайтларына кереп, анкета тутырырга яки үз фикерегезне оешмаларда урнаштырылган «почта тартмаларын»дагы «Шикаятьләр һәм теләкләр» кенәгәсенә язып калдырырга мөмкин.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

Яңа һава юллары ачыла

1 марттан ташламалы авиамаршрутлар старт ала. Алар: Казан – Түбән Новгород – Казан һәм Пермь – Самара – Пермь. Рейсларны финанслауда Татарстан, Самара, Түбән Новгород һәм Пермь өлкәләре катнаша.

2017 елда Татарстанның «ЮВТ АЭРО» авиакомпаниясе барысы 15 субсидияле маршрутларны башкарачак. Апрельдә «Тбилиси – Казан» туры даими рейсы да ачылачак. Кама арты зонасы халкы өчен дә күңелле хәбәрләр бар. «Комиавиатранс» авиакомпаниясе «Бегишево» аэропортыннан Санкт-Петербургка туры рейсларын яңартты. Әлеге маршрутта очышлар атнага ике тапкыр – чәршәмбе һәм җомга көннәрне башкарыла. Очкыч «Пулково» аэропортыннан сәгать 10.05тә күтәрелә, 12.20дә «Бегишево» аэропортына төшә. «Бегишево»дан 13.20дә очып китә һәм Пулковода 15.45тә була. Яңа рейс өчен тариф – 6 мең сумнан башлап.

ЯРМИНКӘ

Көз өлгермәсәң, бүген чык

Казан районнарындагы базарлар территориясендә агропредприятиеләр белән фермерлар һәр шимбәдә кече ярминкәләр оештыра. Фермерлар өчен махсус төзелгән тимер чатырларда сәүдә көн саен бара.

Дамир БӘДРИЕВ

Автор фотосы

– Кукмара районының Адай авылында ирем Айдар белән бергәләп кәбестә, суган, кишер үстерәбез. Маллар да асрыйбыз. Казанга ярминкәләргә бик теләп киләбез, – ди Илнария Шакирова.

Яңа Савин районындагы базарда Татарстанның халык артисты Азат Тимершаех очрады.

– Тула өлкәсендә булып кайткан идем, аларда азык-төлек бәяләре бездәгегә караганда шактый кыйбат, – диде җырчы. – Татарстан җитәкчелегенең шушындый ярминкәләр оештыруын хуплыйм. Бәяләр кибеттәгедән арзан, ә иң мөһиме – республикада җитештерелгән продукцияне ышанып сатып алабыз. Агропредприятиеләргә, авыл хезмәтчәннәренә чын күңелемнән рәхмәт! Җаның ни тели – шул бар. Хөкүмәт яшелчә, җиләк-җимеш үстерүчеләргә дә ярдәм күрсәтсен иде.

Чатырлар урнашкан адреслар:
Фучик урамы, 64;
Липатов урамы, 7;
Зәкиев урамы, 12;
Дементьев урамы, 7;
Беломорская һәм Гудованцев урамнары чаты;
Батыршин урамы, 20;
Лаврентьев урамы, 10.

Сәүдә иртәнге 7.00дән көндезге 12.00гә кадәр.

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

Банкларда хәлләр яхшырачак

Татарстан Республикасы прокуроры Илдус Нәфыйковның матбугат конференциясендә журналистлар белән әңгәмәсе банклар темасыннан башланды.

БАНК

– «Татфондбанк» белән бәйле эш уңай тәмамланыр, дип өметләнәбез. «ТФБ Финанс»ның өч җитәкчесе, ә «Татфондбанк»ның бер җитәкчесе кулга алынуы законлы. Хәзер җентекләп тикшерү эшләре бара. Банкларга кереп тикшерүләр үткәреп йөрмәячәкбез. Банкларда прокурорның күренүе, банк системасына карата әйтелгән ялгыш сүз паника тудырырга мөмкин, – диде прокурор.

Ул саклык акчаларны иминиятләштерелгән банкларга салырга киңәш итте. Берәр хәл килеп чыкса, иминиятләштерелгән 1 миллион 400 мең сум акчаңны гарантияле ала аласың.

АФРИКА СТУДЕНТЫ

Казанда 17 февральгә каршы төндә Гадел Кутуй урамындагы 1нче йорт янында ир-ат мәете табыла. Аның Африканың Чад Республикасыннан килеп, федераль университетның юридик факультетында укыган 24 яшьлек студент икәнлеге ачыклана. Бичара егеткә пычак белән 20 мәртәбә кадаганнар.

Прокурор әйтүенчә, тикшерү эше башланган, инде беренчел нәтиҗәләр бар.

ЧЕГӘН КАЙГЫСЫ

Яшел Үзән районы халкы Айшә һәм Нижние Вязовые авылларында яшәүче чегән төркемнәреннән зарлана.

– Татарстан җирлегендә меңнәрчә ел элек тә татарлар, руслар, әрмәннәр, яһүдләр, чувашлар, марилар, удмуртлар янәшә яшәгән, сәүдә иткән. Татарстанда бүген дә халыклар арасында дуслык хакимлек итә, һәр милләт хөрмәткә лаек. Чегәннәр дә хөрмәткә лаек. Ләкин һәр кеше законнарны үтәргә тиеш, – диде Илдус Нәфыйков.

КОМПЬЮТЕР ЮЛӘРЛӘНДЕРӘ

– Кызганыч, замана балалары яртылаш виртуаль дөньяда яши, – дип, фикерләре белән уртаклашты прокурор. – Интернетка тәрле уеннар куела, аларның кайберләре бала акылына тискәре йогынты ясый. Без кеше сәламәтлегенә куркыныч тудыручы бит-сайтларны күзәтеп торабыз, Роскомнадзорга хәбәр итәбез. Узган ел зарарлы 25 мең битнең эшчәнлеге ябылды. Баланы ипташләре белән турыдан-туры аралаштырырга, чынбарлыктагы тормышка тәрбияләргә тырышырга кирәк. Бала гел компьютерга, планшетка, гаджетка капланып утырса, аның психикасы чынбарлыктан, ягъни тормыштан аерыла башлый.

ХЕЗМӘТ ХАКЫ

– Халыкка хезмәт хакларын вакытында түләүне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шәхсән үзе дә, прокуратура да күзәтчелектә тота. Хезмәт хакын өч ай түләмәдең икән, ул инде кар йомармасы кебек зурайганнан-зурая. Бу инде предприятиенең банкротлыкка чыга баруы билгесе. Республикада хезмәт хакы бурычларын киметүгә ирешелде. Әйткәнемчә, мәсьәлә игътибар үзәгендә, – диде Илдус Нәфыйков.

Рәдиф КАРАГАЙ.

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

Ярыш кына түгел

Татарстан Республикасы премьер-министры вазифасын вакытлыча башкаручы Алексей Песошин «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионаты җиңүчеләре белән очрашты. Бу егетләр һәм кызлар республика данын 16-19 май көннәрендә Краснодар шәһәрендә узачак «WorldSkills Russia» ил күләмендәге ярышларда яклаячак.

Финалга чыгучылар исә 14-19 октябрьдә Әбу-Даби шәһәрендә дөнья беренчелегендә катнаша. Республикабыз Россия сайлап алу турларында 76 компетенция буенча ярышачак.

– Татарстанда «WorldSkills» хәрәкәтенә кушылучылар саны елдан-ел арта. Быел төбәк этабында меңнән артык яшь белгеч көч сынашты. Ышанам, бу залда утыручы һәр кеше үз осталыгын, сәләтен тиешенчә күрсәтә алды. 2019 елда Казан Бөтендөнья эшче һөнәрләр чемпионатын кабул итәчәк. Анда күбегез катнашыр дип өметләнәм. Россия җиңәргә, ә безнең конкурсантларның күрсәткечләре иң яхшысы булырга тиеш. Чемпионат хәрәкәте җәелеп китсен өчен, җитәкчеләр тарафыннан зур эш башкарыла. «WorldSkills» безнең өчен ярыш кына түгел, ул – эшче һөнәрләрнең дәрәҗәсен арттыру, сыйфатын күтәрү коралы, – диде Алексей Песошин.

Хәзерге вакытта «WorldSkills» хәрәкәтенә Россиянең 84 төбәге кушылган. Ил буенча 60 мең конкурсант һәм эксперт катнаша.

Агач исен яратсаң

Республика яшьләре үз уңышлары белән сөендерүен дәвам итә. Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллияте укучысы Раил Шәрипҗанов, Мәскәүдә «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионатының «Агач остасы» (краснодеревщик) компетенциясендә сынауларны уңышлы гына үтеп, Россия җыелма командасына керде. Төбәкләр буенча җыелган иң көчле 28 катнашучы арасында ул лаеклы җиденче урынны алды.

– Бездә практика икенче курстан гына башлана. Яхшы нәтиҗәләр күрсәткәч, чемпионатта көч сынап карарга тәкъдим иттеләр. Бу – беренче тәҗрибәм. Әлеге ярышларда 22 сәгать дәвамында тумбочка ясадык. Без бүк белән нарат агачын кулланырга тиеш идек. Нарат җиңел эшкәртелә, ә менә бүк белән бераз җәфаланырга туры килде, – дип елмая җиңүче егет.

Раилнең эшләре республикада иң яхшысы булып таныла. Мәскәүдә исә яшь осталар сигез сәгать эчендә эш өстәле ясарга тиеш була.

– Мәктәптә укыганда никтер аш-су остасы буласым килгән иде. Зуррак сыйныфларда каникул вакытында үземне төзелештә сынап карадым. Шунда төзүче һөнәре белән кызыксынып киттем. Үзем шәһәрдә туып-үстем. Арча районында яшәүче бабам да балта остасы, агач эшләренә хирыслык шуннан күчкәндер инде. Агачның чисталыгын, исен яратам, – ди Раил Шәрипҗанов.

Машиналар хирургы

«WorldSkills» чемпионатында урта һөнәри белем бирү йортлары гына түгел, ә югары уку йортлары да катнаша ала. Казан дәүләт аграр университеты студенты Илнур Хәйбрахманов быел үзен «Авыл хуҗалыгы машиналарын куллану» юнәлешендә сынап караган.

Илнур тумышы белән Азнакай районы Актүбә бистәсе егете. Әтисе – нефть өлкәсендә эретеп ябыштыручы, әнисе тәрбияче булып эшли.

– Авылда туып-үскән егет бит мин, техниканы күргән кеше. Кечкенәдән әти, бабай белән һәрвакыт машинада казына идем. Чемпионатта җиңүемдә шул тәҗрибәм зур роль уйнагандыр, – дип елмая егет.

Ярышларда ул техниканың җитешсез якларын табып, аларны төзәтергә тиеш була. Мәсәлән, биремнәрнең берсе – двигательдәге клапанны көйләү. Барлык биремнәрне вакытында һәм тиешле дәрәҗәдә эшләп чыгу өчен техниканы энәсеннән-җебенә кадәр белергә кирәк. Илнур үз эшенә хирург төгәллеге белән карый. Бер генә детален дөрес төзәтмәсәң дә, машина бөтенләй дә эшләмәскә мөмкин бит.

– Инде авыл хуҗалыгында да үз көчемне сынап карадым. Узган ел уку йортыннан Менделеевскига практикага җибәрделәр. Механик булып эшләдем. Бу тагын да канатландырып җибәрде. Мондый чемпионатлар кирәк, чөнки авыл хуҗалагында эшләүче яшьләргә профессиональ мөмкинлекләрен сынап карау өчен андый ярышлар сирәк, – диде Илнур.

Алисә САБИРОВА әзерләде

Сәләт – мөмкинлекләр мохите

«Сәләт» яшьләр оешмасы ел саен төрле өлкәдә уңышларга ирешкән «сәлкеш»ләрне «Сәмрух» премиясе белән бүләкли. Бу – еллык эшкә нәтиҗә ясау чарасы да.

Премия «Сәләт» иҗтимагый яшьләр фонды һәм республиканың Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән берлектә оештырыла. Узган ел «Сәләт» проектларында 12 меңнән артык сәләтле балалар һәм яшьләр катнашкан. Иң-иңнәре исә җиңүчеләр дип табылды. Быел беренче тапкыр өч «сәлкеш»кә махсус «Сәләт» стипендиясен тапшырдылар. Әлеге бүләккә Чулпан Фатыйхова, Гүзәл Гайнанова һәм Ләйсән Сабитова лаек булды. Кызларны «Сәләт» фонды башкарма директоры Тимур Сөләйманов тәбрикләде.

– Бүген «Сәләт» шундый, чөнки сез шундый. Без һәрвакыт нәкъ сезнең кебек тагын да әйбәтрәк булырга омтылабыз, – диде ул.

Кичәнең алып баручылары – кайчандыр үзләре дә «Сәләт» аланнарында ял иткән Гөлназ Сафәрова белән Фәнил Ваккасов та «сәлкеш»ләргә кызыкты булса кирәк:

– Ни өчен 2005 елда да мондый премия булмады икән, – дип көрсенде Фәнил.

– Ул вакытта җиңәргә күпкә җиңелрәк булыр иде. Хәзерге «сәлкеш»ләр арасында көндәшлек зур. Үн ел эчендә «Сәләт»нең 25 аланы барлыкка килде, – диде Гөлназ.

Балык Бистәсе районының Югары Тегермәнлек урта мәктәбе укучылары, үзләреннән шактый тәҗрибәлерәк көндәшләрен узып, «Ел паблигы» номинациясендә җиңү яулады. Ә «Ел клубы» дип соңгы вакытта актив эшли башлаган «Сәләт – Самара» клубы билгеләнде. Бу әле яңа номинция.

Дүрт лауреат арасыннан иң яхшы «Ел әйдаманы» дип «Сәләт – Батыр» аланы егете Фәннур Шәйхетдинов сайлап алынды. «Ел өлкән әйдаманы» номинациясендә Диләрә Хәлитова җиңде.

«Сәләт» тарихына күз салсак, ике дистә ел эчендә 500дән артык җыр язылган. Ә 2016 ел бөтенләй җырлар «бумы»: «сәлкеш»ләр 26 яңа җыр иҗат иткән. Яшьләрнең бу сәләтенә композитор, Муса Җәлил премиясе лауреаты Эльмир Низамов та сокланды.

– Мин көй генә иҗат итәм, ә сез көйне дә, сүзләрен дә язасыз, үзегез шуны башкарасыз да, – диде ул.

«Сәләт җырлый» номинациясендә үзе язган җыры белән автор-башкаручы Энҗе Әхмәтҗанова җиңеп чыкты. Аңа «Rocket records» тавыш яздыру студиясендә җыр яздыру мөмкинлеге бирелде.

Дәрес, үз җиңүләре белән килешмәүчеләр дә бар иде. «Ел директоры» номинациясендә беренче урын алган Альбина Кадыйрова җиңүен дусты Таһир Насыйбуллин белән уртаклашты. Бу исә «сәлкеш»ләрнең бер гаилә кебек туганлашып яшәүләрен күрсәтә. Иң самими юнәлешләрнең берсе – «Ел сәлкеше». Бирелә Айгөл Шакирова җиңде.

«Сәлкеш»ләр үзләренә төпле киңәшләрен биргән «аксакал»ларын да онытмый. Тимур Сөләйманов «Сәләт»нең дуслары булган язучы Рабит Батулланы, тарихчы-галим Индус Таһировны «Ел остазы» номинациясендә бүләкләде.

– Телебез, милләтебез бетә, дип, әле иртә белән генә борчылган идем. Монда килгәч, алай түгел икәнен аңладым. «Сәләт» булганда, милләт яшәячәк. Бу яшьләр мондагы җиңүләре белән генә тукталмаячак, алар – Президент буласы кешеләр, – диде Рабит Батулла.

«Җәй» балалар һәм яшүсмерләр сәламәтлеген оештыру оешмасы «Ел партнеры» исеменә лаек булды. Елның иң шәп аланы дип «Сәләт – Рухият» билгеләнде.

Җиңүчеләргә «Сәмрух» сыны, дипломнан тыш, Fund.selet.biz мәйданчыгында акча җыю нәтиҗәләре буенча билгеләнәчәк акчалата премия дә каралган.

Резеда САДРИЕВА.

Сөекле Моңсара апабызны искә алып...

http://mincult.tatarstan.ru

Төп бүләк Арчага китте

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте үз укучылары арасында үткәргән «Язылган өчен телевизор» бәйгесенә йомгак ясады. Исегезгә төшерәбез, бәйгедә 2017 елның беренче яртыеллыгына, кимендә, өч басмага язылган абунәчеләр катнашты. Татарстанның 39 районыннан барлыгы 213 гариза кабул ителгән. Шулай ук Башкортстан, Әстерхан һәм Пенза өлкәләреннән дә катнашучылар булган.

Оештыручылар әйткәнчә, бәйгедә Вәлиева фамилияле алты кеше катнашкан. Шуларның дүртесе – үз районнары тормышында бик актив катнашучылар. Аларга «ТАТМЕДИА»ның махсус бүләкләре тапшырылды.

– Әлеге акция алтынчы тапкыр уздырыла. Абунәчеләребезгә зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Мондый чаралар киләчәктә дә оештырылыр дип өметләнәм. Укучыларыбыз арасында бишалты басмага язылучылар бар. Ә бер тугры дустыбызның өенә инде берничә ел рәттән 10-11 газета-журнал килеп тора, – диде «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры урынбасары Әлфия Адиятова.

Җиңүчеләр катнашучыларның тәртип номерларын уйнату юлы белән ачыкланды. Бәйгедә ун таба, өч фотоаппарат һәм төп приз – телевизор уйнатылды. Әлеге зур бүләк Арчада яшәүче Фирдания Мифтахетдиновага китте. Шунысы уңайлы: бүләкләрне алыр өчен, җиңүчеләргә Казанга килеп йөрергә кирәк булмаячак. Алары һәр

АБУНӘ – 2017

район газетасы редакцияләреннән алып китәргә мөмкин. Ә республикадан читтә яшәүчеләргә почта аша җибәреләчәк.

Бәйрәм рухын алган әлеге чарага өч абунәче дә чакырылган иде. Шуларның берсе – 78 яшьлек Галишан Нуриәхмәт, мәсәлән, сигез басмага язылган. Алар арасында «Шәһри Казан» газетасы да бар.

– «Шәһри Казан»ны беренче саныннан ук укыйм. Мин газеталарда милләт язмышын, татар халкының үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген яктырткан язмаларны укырга яратам. Шуңа күрә сезнең газетада да иң беренче чиратта проблемаларны күтәреп чыккан житди мәкаләләрне эзлим, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

Реклама, 16+
Акциянең вакыты: 2016 елның 20 октябреннән 2017 елның 20 мартына кадәр.
Тулырак мәгълүмат www.tatmedia.ru сайтында.

Каюм Насыйрида кунакта

Яшел Үзән районының Кече Шырдан авылы үзенең якташы – танылган мәгърифәтче, галим Каюм Насыйри белән горурланып яши. Ел саен, Каюм Насыйриның туган көне уңаеннан, аның истәлегенә һәм бакыйлыкка күчкән авылдашлары рухына Коръән ашы уздырыла. Менә инде өченче ел рәттән, Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә, «Каюм Насыйри туган җирне яңартып торгызу» фонды галимнең әдәби мирасын барлауга багышланган төбәкара бәйге оештыра.

Эльвира МОЗАФФАР

ХӘТЕР

Быел Каюм Насыйриның тууына – 192 ел. Әлеге дата уңаеннан, Кече Шырданга галимнәр, укытучылар, кунаклар кайтты. Әдәби-музыкаль кичә белән башланган чара барышында бәйгедә җиңүчеләрне дә бүләкләделәр. Бәйгегә мәгърифәтчегә һәм аның туган авылына багышлап иҗат ителгән шигырьләр, Каюм Насыйриның әдәби әсәрләре башкарылган видеоязмалар – барлыгы 70кә якын эш кабул ителгән. Катнашучылар Татарстанның төрле район-шәһәрләреннән: Саба, Кайбыч, Яшел Үзән, Бөгелмә, Казан, шул ук вакытта Башкортстан, Чувашия, Мари Эл республикаларыннан. Бәйрәм кичәсе җиңүчеләрне бүләкләү, Каюм Насыйри турындагы истәлекләр, җыр, нәфис сүз, чыгышлар белән үрелеп барды. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Данис Шакиров әлеге чараны оештыруда башлап йөрүче «Каюм Насыйри туган җирне яңартып торгызу» фондының башкарма директоры Асия Гобәйдуллинага һәм бу эштә күп көч куйган укытучы, Кече Шырдан авыл клубы мөдире Рамил Шакировка конгресс исеменнән Рәхмәт хатлары тапшырды.

– Бәйгегә тапшырылган эшләр географиясе ягыннан бик киң, эшләр дә тирән эчтәлекле. Берничә кеше башлангычында шундый зур эш башкарылган. Мине иң дулкынландырган әйбер ул – кеше факторы. Асия Наил кызының башкарган эшләре үрнәк алырлык, ә укучым – кичәне алып баручы Рамил Шакировны үзем өчен яңа яктан ачтым. Ул бүген үзе укытучы. Ихласлыгын, ике телдә дә камил сөйләшүен, чын укытучы булып формалашуын күреп, күзәмә яшьләр килде. Мин аның белән горурланам, – ди Казанның Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2нче гимназиясе директоры Камәрия Хәмидуллина.

Кече Шырдан – урамнарын, тыкрыкларын элек заманнардан бирле үзгәртмичә саклап калган борынгы авылларның берсе. Ул әле дә Каюм Насыйри эзләрен саклый. Мәгърифәтченең бюсты урнаштырылган. Күрше Олы Ачасыр авылында аның исемен йөрткән музей эшли. Кече Шырдандагы Каюм коесы да сакланган. 1902 елда Каюм Насыйри авылда мәчет салдырган. Совет чорында, манарасы киселгәч, 1972 елга кадәр ул мәктәп булып хезмәт итә. Соңрак бинаны күчергәч, анда китапханә, медицина пункты урнаша. Бу бинаны саклап калу максатыннан, 2013 елда шырданлылар аны кабат мәчет итеп торгызырга карар кылалар. Бүген бирегә эш гөрли. Тиздән Кече Шырданда Каюм Насыйриның яңартылган мәчетен ачарга җыеналар.

– Каюм Насыйриның туган авылын чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез кунакка кайтырлык һәм башка туристларны да җәлеп итәрлек дәрәҗәгә үстерәсебез килә. Соңгы ике елда авылда күп эш эшләнде: чишмәләр торгызылды, тиздән мәчет сафка басар, иншалла. Мәчет белән генә чикләнеп калырга уйламыйбыз. Элеккеге мәктәп бинасын яңартып, анда китапханә, музей оештырырга ниятлибез. Бу бина туристларны кабул итәрлек иҗтимагый үзәк булыр иде, – ди Асия Гобәйдуллина.

Билгеле булганча, Каюм Насыйриның Зөя өязе авыллары тарихы турында хезмәте бар. Ул ел саен җәй көне авылга кайта торган булган. Вакытын Зөя өязе салалары этнографиясен, тарихын һәм археологиясен өйрәнүгә багышлаган, шифалы үсемлекләрне файдалануга кагылышлы материаллар туплаган. Асия ханым: «Бу авыллар тарихын өйрәнүне дәвам итәргә кирәк», – ди. Фикерне галим Зөфәр Рәмиев тә хуплады.

– Шырдан гына түгел, Каюм Насыйри хезмәтләрендә әйтелгән башка авыллар тарихы буенча да эзләнү эшләре башларга кирәк. Бу уңайдан кызыклы, тарихи яктан исбатланган, әлегә кадәр беркемгә билгеле булмаган материаллар, фәнни эшләр бәйгесен башлыйбыз. Әйтик, үзебезнең Шырдан авылы Идел буе Болгар дәүләте таркалганчы ук барлыкка килгән, дигән фикерләр бар. Моны ничек исбатларга? 1861 елга кадәр Шырдан җирендә хаким иткән алпавытлар кемнәр алар? 1917 елдан соң авылда булган үзгәрешләрне тикшереп язучы да юк. Безнең яклар – бай тарихлы, җәмгыятьтә булган барлык вакыйгаларның шаһиты. Ел дәвамында барачак бу бәйгегә дип әзерләнгән материаллар авыллар тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертер иде, – диде Асия Гобәйдуллина.

Әдәби кичә авыл клубында узды. Барлык кунаклар да мич белән җылытылган бу агач мәдәният йортын үзенә күрә бер тарихи объект, музей буларак кабул итте бугай. Югыйсә, интерактив такталар, компьютерлар белән дә җиһазландырылган бина.

– Бу мәдәният йортын күреп, балачагыма кайткандай булдым. Шул ук вакытта ул заманчалашкан да. XX гасыр белән XXI гасыр тәңгәлләшкән диярсең! 30 ел элеккеге дә, бүгенге дә бина бер хәлдә. Каюм Насыйриның туган авылы – тарихи урын, аны һич тә югалтырга ярамый, биредә яшьләрне җәлеп итү юлларын табарга, авылның киләчәген өметле итәргә кирәк, – ди Камәрия Хәмидуллина да.

Бөек шәхесебез – танылган мәгърифәтче Каюм Насыйриның исемен мәңгеләштерүгә зур тырышлык куйган, аның мирасын барлаган авыл халкы күбрәккә лаек, әлбәттә. Шырданлылар күп нәрсәне үз көчләре белән башкара. «Каюм Насыйри туган җирне яңартып торгызу» фондына җитәкчеләребез дә ярдәм кулы сузса, бу өлкәдә шактый алга китеш булыр иде. Зур тарихны саклаган борынгы авылны, Каюм Насыйриның туган җирен торгызуга битараф калмыйк.

«Әлмәндәр варислары»

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтында СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров истәлегенә багышланган «Әлмәндәр варислары» дигән II халыкара театр фестивале узды.

Ачылу тантанасында күренекле артистның: «Гомерем буе татар халкына хезмәт иттем. Шул халыкка хезмәт итүемә горурланам», – дигән сүзләре экраннан яңгырады. Ректор Рифкат Йосыпов бөек артист исеме белән аталган фестивальнең югары дәрәҗәдә үтәргә тиешлегенә басым ясады. Чара турында Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә җиткерүен һәм уңышлар теләвен дә әйтте. Өч яшьлек Арслан Сибгатуллин, «Туган тел» шигырен сөйләп, фестивальне ачып җибәрде. Балалар спектакльләрдә бик бирелеп уйныйлар. 16нчы гимназиядә театр түгәрәге җитәкчесе Роза Ибәтова укучылары белән Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» спектаклен сәхнәләштергән. Ул 20 ел буе балаларга сәхнә серләрен өйрәтә. Рөстәм Хәсәншин (Акчурин ролендә), Аделина Минһаҗева (Нәфисә) һәм Булат Габдрахмановның (Тукай) сәхнәне яратулары сизелеп тора. Аларга Туфан Миңнуллинның хатыны Нәҗибә Ихсанова белән кызы Әлфия Миңнуллина үзләренең махсус бүләкләрен тапшырдылар.

Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин җитәкчелегендәге жюри балаларның чыгышын гадел бәяләргә тырышты. Беренче урынга Мамадыштан Марат Баязитов җитәкчелегендәге «Хыял» театры лаек булды. Икенче урын Киров шәһәре укучыларына бирелде. Өченче урынны Мари Эл Республикасыннан килгән коллектив һәм Казанның «Велосипед» дигән театр студиясе балалары бүлеште.

Фестиваль кунаклары арасында Шәүкәт Биктимеровның балалары Искәндәр Биктимеров белән Гүзәл Гыймранова, бертуган энесе Җәүдәт әфәнде дә бар иде.

– Мин дулкынланып, елап та алдым. Әти турында йөрәк түрендә сакланган хатирәләр кузгалды. Киләсе елга әтинең 90 еллыгы. Аны онытмаулары, искә алулары өчен рәхмәт. Сәнгатькә гашыйк балалар арасында бәлки Әлмәндәр дә килеп чыгар әле. Институтта укучы егет ул рольне бик оста уйнады, – диде Гүзәл ханым.

– Бу фестиваль артист турында хатирәләрне, татар мәдәниятен, телне саклый. Яңа талантларны барлый. Аны оештыручыларга рәхмәт, – ди Искәндәр әфәнде.

Шәүкәт Биктимеровның энесе Җәүдәт әлеге фестивальнең дәвамлы булуын тели. Үзенең яшьлек елларын искә төшереп алды ул. Заманында ул артист булырга теләгән. Тик Шәүкәт абыйсы: «Бер гаиләдә ике артист булмый», – дип каршы килгән. Ул киләчәктә Шәүкәт Биктимеров яшәгән йортка истәлек-тактасы куелуын һәм аның исеме белән Казанда берәр урам аталуын тели.

КАЗАНСКИЙ ЗАВОД СИЛИКАТНЫХ СТЕНОВЫХ МАТЕРИАЛОВ
КИРПИЧ от 8,24 р./шт.
5-707-909
5-719-259
www.kzssm.ru
ГАЗОБЕТОН от 50,40 р./шт.
ЖБИ изделия
ОТГРУЗКА КРУГЛОСУТОЧНО
Реклама

Новые достижения в комплексной защите семян

Важнейшим периодом в вегетации яровых культур является стадия всходы-кущение. Именно в это время и формируется потенциал будущего урожая. Засуха, даже самая незначительная, не позволяет растению формировать развитую корневую систему. На этом фоне патогенные микроорганизмы, находящиеся на семенном материале, в почве и на растительных остатках предшествующей культуры только усугубляют ситуацию на формирование корневой системы культуры.

Фунгицидные обработки по вегетации – малоэффективный приём в борьбе с корневыми и прикорневыми гнилями, т.к. активное вещество препарата не способно передвигаться по флоэме растения в корневую зону и блокировать заболевания. После обработки семенного материала действующее вещество передвигается вместе с новым приростом и адсорбируется корневой системой, что позволяет блокировать инфекционное начало от момента прорастания семени до стадии кущения.

Очень важно, чтобы защита была не только эффективной, но и бережной, не вызывая задержки всходов и не тормозя ростовые процессы на самых ранних этапах прорастания семян. Зачастую триазольная группа в составе препаратов для защиты семян в той или иной мере может повлиять на торможение выхода проростка на поверхность почвы и получения дружных всходов. Поэтому нужно учитывать, какие триазолы и какое их количество содержится в продукте для защиты семян. На сегодняшний день самым мягким триазолом по отношению к культуре является дифеноконазол, который составляет основу продуктов ДИВИДЕНД® ЭКСТРИМ и ДИВИДЕНД® СУПРИМ.

Производственное использование препарата неоднократно доказало, что биологическая эффективность продукта ДИВИДЕНД® ЭКСТРИМ против основного патогенного комплекса на семенном материале и в посеве составляет 90–100% *(табл. 1)*.

ПРЕИМУЩЕСТВА ДИВИДЕНД® ЭКСТРИМ:

- получение дружных всходов в широком диапазоне сроков сева (от ранних до поздних);
- эффективный контроль самых распространенных болезней зерновых культур: альтернариоза, питиозной и гельминтоспориозной корневых гнилей за счет высокой эффективности дифеноконазола и мефеноксама;
- дифеноконазол оказывает самое мягкое воздействие на культуру, не вызывая ретардантного эффекта, что способствует получению дружных всходов даже в засушливых условиях;
- сохранение препарата на семенах после обработки и до момента прорастания за счет надежной технологии «Формула М»;
- ДИВИДЕНД® ЭКСТРИМ сохраняет урожай в среднем на 2–6 ц/га по отношению к варианту хозяйства, что позволяет окупить затраты на обработку семян более, чем в 3 раза. Этот эффект достигается за счет увеличения коэффициента кущения более, чем в 2 раза, снижения нормы высева в среднем на 15%.

В текущем сезоне компания «Сингента» представила новинку в обработке семян колосовых культур – ДИВИДЕНД® СУПРИМ.

ДИВИДЕНД® СУПРИМ (92,3 г/л тиаметоксама, 36,92 г/л дифеноконазола, 3,08 г/л мефеноксама) предназначен для защиты интенсивных сортов яровой и озимой пшеницы от альтернариозной семенной инфекции, корневых гнилей, включая питиозную, основных почвенных и наземных вредителей в дозировках 2,0–2,5 л/т. За счёт высокой концентрации фунгицидной составляющей (в дозировке 2,5 л/т сопоставимо по дифеноконазолу с обработкой ДИВИДЕНД® СТАР 3,0 л/т) продукт обладает продолжительной защитой против гельминтоспориозной корневой гнили. Даже при такой концентрации триазольного компонента продукт не обладает негативным ретардантным эффектом, присущим некоторым триазолам.

ПРЕИМУЩЕСТВА ДИВИДЕНД® СУПРИМ:

- готовый инсектицидно-фунгицидный продукт, не требующий смешивания и исключающий все возможные ошибки при приготовлении баковых смесей;
- пролонгированная защита от корневых гнилей, включая питиозную, и различных видов головни, включая карликовую головню пшеницы;
- уникальное сочетание эффекта 3-х действующих веществ из разных химических классов: дифеноконазола – самого мягкого триазола, мефеноксама, предотвращающего заражение почвенной инфекцией, тиаметоксама, стимулирующего развитие растения и ускорение прохождения фаз развития в стрессовых условиях (лимит влаги);
- прочная формуляция отлично удерживает дополнительные ингредиенты: микроудобрения, гуматы и другие биостимуляторы;
- эффект жизненной силы (Vigor™-эффект) увеличивает стрессоустойчивость растений к дефициту влаги на ранних этапах развития, переуплотнению и низкой кислотности почв.

ТАБЛИЦА 1

БИОЛОГИЧЕСКАЯ ЭФФЕКТИВНОСТЬ ДИВИДЕНД® ЭКСТРИМ (%) ПРОТИВ ОСНОВНОГО ПАТОГЕННОГО КОМПЛЕКСА НА СЕМЕННОМ МАТЕРИАЛЕ И В ПОСЕВАХ ЯРОВОЙ ПШЕНИЦЫ. ЛИПЕЦКАЯ ОБЛАСТЬ, СТАНЦИЯ ИССЛЕДОВАНИЙ КОМПАНИИ «СИНГЕНТА». 2012-2015 ГГ.

	Семенная инфекция		Инфекция в посеве (стадия BBCH = 27-29)	
Вариант опыта	Виды альтернариоза	Виды аспергиллиоза	Виды фузариума	Виды гельминтоспориоза
ДИВИДЕНД® СТАР 1,0 л/т	90%	88%	78%	95%
ДИВИДЕНД® ЭКСТРИМ 0,5 л/т	95%	91%	83%	92%
ДИВИДЕНД® ЭКСТРИМ 0,8 л/т	100%	98%	92%	100%
2-х компонентный триазольный продукт	95%	94%	85%	90%

HCP05 = 1.12

Яровая пшеница Грани. 2014 г. Станция R&D ООО «Сингента»
Попов Д.Ю. технический эксперт по защите семян компании «Сингента, к. с.-х. н.

на правах рекламы

Люция Галләмова: «Бөтен барлыгым белән театрда»

Моннан ун ел элек Татарстанның атказанган артисты Люция Галләмованың Камал театрында узган 50 яшьлек юбилеенда булган идем. Бу әңгәмәдә ул юбилей хакында бераз сүз булыр әле. Сәхнәгә Люцияне котларга чыккач, Камал театрының ул чактагы директоры Шамил Закиров әйткән сүзләр хәтеремдә: «Люция – гомерен театрга багышлаган, театр дип яши торган кеше. Аның башка тормышы юк. Юбилеен татарның төп театры булган Камал театрында уздырырга аның татар артисты буларак хакы бар», – дигән иде ул. Артист хакы дигән сүз – нинди зур һәм матур сүз бит. Чынлыкта, бер театр артистының икенче театр сәхнәсендә юбилей уздыруы гадәти хәл түгел. Театр дөньясына якын кеше бу хакта белә инде. Ләкин очрагына карап мөмкин хәл икән... Шамил Зиннуровичның киң күңеленә мәдхия булып, минем күңелдә әле дә яши бу очрак. Әлбәттә, Люция хәтерендә дә яши ул...

– Люция, син шундый хатын, башкаларда тыныч, проблемасыз узган юбилейлар синдә һәрчак көтелмәгән борчулар, мәшәкатьләр, киртәләр белән уза. Моннан ун ел элек, 50 яшьлек юбилеең вакытында, Тинчурин театрында янгын чыгып, ул ремонтка ябылган иде. Инде бу юбилееңда – кичәңә тәгаенләнгән «Алтын көз» спектаклендәге партнерың Тимер Зиннуров капыл вафат булды...

– 50 яшьлек юбилеемны, үзебезнең театр ремонтта булу сәбәпле, башта кичектереп торырга да уйлаган идем. Директорыбыз Фәнис Мөсәгыйтов ул чакта: «Юк, кичектермибез, берәр җай эзлибез», – диде. Бервакыт ниндидер бер чарада урыным Камал театрының ул чактагы директоры Шамил Закиров белән янәшә туры килде. Әлеге дә баягы юбилей темасына кагылгач, Шамил Зиннурович: «Мин сиңа театрны бирәм, Люция, безнең театрда уздыр», – диде. Матур гына узды ул юбилеем. Быел 60 яшьлек юбилеем әзерләнеп беткән иде. Тынычлап көтеп йөрим. Кадрлар бүлегеннән Тимернең вафатын әйтеп шалтыраткач, үземә дә чак кына инфаркт булмады. Режиссерым Рәшит Заһидуллин: «Борчылма, Люция, спектакльне алмаштырмыйбыз. Ролең уңышлы, спектакльгә Илгизәр Хәсәновны кертәбез», – диде. Берничә атна буена туктаусыз репетиция ясадык, Аллага шөкер, спектакльне алыштырырга туры килмәде. 25 февральдә юбилеема багышлап уйныйбыз инде.

– Сине күпләр бары театр артисты итеп хәтерли. Ләкин биографияңдә Татар филармониясе белән бәйле еллар да бар бит.

– Әйе, бар. Училищеда мин Марсель Сәлимҗанов белән Шәхсәнәм Әсфәндиярова курсында укыдым. Сәхнә теленнән Асия апа Хәйруллина укытты. Без укырга кергән елны барлыгы 280 кеше килгән иде, 24 кешене алдылар. Укуны тәмамлаганда, 18гә калдык. Хәзер театрда безнең курсны тәмамлаган өч кеше калды – Илгизәр Хәсәнов, Әсхәт Хисмәтов һәм мин. Икенче курста укыганда ук филармониягә конферансье итеп чакырдылар. Филармониянең алып баручылары Туниска бик мөһим чарага киткәч, концертлар алып барырга кеше кирәк булды. Мин инде мәктәптә укыганда ук интермедияләр, шигырьләр сөйли идем. Әзер материал белән эстрадага җайлы гына кереп киттем. Укып бетергәч, ике җирдән чакыру алдым. Әлбәттә инде, Казанда филармониядә калдым. Вафирә Гыйззәтуллина бригадасында эшли башладым. Аның белән бер ел эшләдем. Әлфия апа Авзалованың алып баручысы Рәшит Сабиров университетта дәүләт имтиханнары бирергә киткәч, аның бригадасында эшләп алдым. Бу да зур сабак һәм тәҗрибә булды. Соңрак Венера Шәрипова, Гали Ильясовлар белән эшләдем. Нинди шәхесләр!

– Шулай да филармония стажың ни өчендер өч елдан артмаган.

– Күчмә театрда эшләгән Рәүф абый Зәйнуллинны очраттым да, ул миңа: «Люция, син нишләп эстрадада йөрисең? Син бит театр артисты», – диде. Шул чакыруның «кулы җиңел» булды, ул чакта әле Кремльдә урнашкан Күчмә театрга килдем. Режиссер Равил Тумашев башта «Трибунал» спектакленә «ввод»ка кертте. Соңрак Аяз абый Гыйләҗев «Шикәрем син, балым син» әсәрен алып килде. Равил абыйның миңа башта бик исе китмәде, аның үзенең яраткан, ышанган артистлары бар иде. Тәслимәгә ул бу әсәрдә Сәрбиназ ролен бирде, ләкин Тәслимә рольдән баш тартты да, ул роль миңа эләкте. Уңышларымның күбесе әнә шулай очраклылыктан тора. Шул спектакльдән соң мин Аяз абыйның яраткан артистына әйләндем. «Ефәк баулы былбыл кош»та Шифан ролен ул инде махсус миңа дип алып килде.

– Иҗатыңда шактый торгынлык чоры да булды. Күп уйнаганнан соң озак вакыт бөтенләй диярлек уйнамый тордың. Хәзер тагын күп уйныйсың. Мондый «сикереш»ләр нәрсә белән бәйле соң?

– Аны аңлатып була. Равил абый киткәч, төрле-төрле режиссерлар белән эшләдек. Рабит Батулла, Празат абый Исәнбәт, аннан соң артистыбыз Зөфәр Харисов та спектакльләр куйгалады. Ике ел театрдан китеп тә тордым, кабат эстрадада, Луиза Батыр-Болгари белән Рамил Миндияр төркемендә эшләп алдым. Театрга режиссер булып Дамир Сираҗиев килде, ләкин ул мине артист буларак «күрмәде». «Йөзең матур, ләкин формага килергә кирәк», – ди иде. Ә мин баладан соң ябыга алмадым, дөресрәге, тырышмадым да. Укыганда ук үземне икенче пландагы характерлы рольләр уйнаучы итеп тәгаенләп куйган идем инде. Комедияләрдә бик күп яхшы рольләрем булды, барысы да күңелемә ятышлы иде. Рольләрем азайгач, аптырап тормадым үзе, спектакльләр оештырырга алындым, өч сезон постановка бүлеге мөдире булдым. Энергиямне куярга урын табып тора идем. Соңрак Исламия апа роль бирде, бик күп «ввод»ларым булды. Күп рольләрем шулай очраклы һәм төрле ситуацияләргә бәйле рәвештә «эләкте».

– Син усал, бозык, азгын хатыннар рольләрендә күп уйнадың. Кыяфәтең бик үк юаш булмаганлыгыңны әйтеп торса да, аралашканда, гаҗәеп ачык, хәтта кирәгеннән артык ихлас кеше син. Героиняларың өчен буяулар табып бетерү җиңел түгелдер?

– Үземнең усал түгеллегемне, беләсеңме, кайчан аңладым? Моннан биш ел элек икенче тапкыр кияүгә чыккан идем бит, үземнең әрләшә белмәвемне шунда аңладым. «Дөп» иттереп кистереп әйтәм дә туктыйм, ызгышып тормыйм. «Яшь ирем» бу эшкә шулкадәр оста булып чыкты. Теле телгә йокмый, «те-те-те-те» генә килеп тора. Автоматтан аткан кебек. Мин әйтәм дә онытам, хәсәтләнеп, ачу саклап йөрмим. Менә шул – олыгайган көндә үземә капма-каршы образлы «яр» тапкан булып чыктым. Ярый инде яхшы булды, озак интекмичә, икебез ике якка киттек. Образы хәтердә калды, берәр роль уйнаганда ярап куяр. Героиняларымны да шулай – үземнең таныш кешеләрне прототип итеп алып, холыкларын өйрәнеп тудырам. Спектакль караганда, күбесе үзләрен таныйлар да.

– Син дә ир җилкәсе артына качып, алып кайтканны турап, алып биргәнне киеп кенә яши алыр идең. Ләкин синең – чибәр, уңган, тырыш хатынның шәхси бәхете бигрәк «киртәле»...

– Беренче ирем белән аерылышуны авыр еллар – 90нчы еллардагы кризис белән бәйлим. Ул театрда машина йөртүче булып эшли иде. Матур гына яши идек, фатир да алдык. Акча җитмәү бәласе – ирем кирәкмәс эш, юньсез кешеләр белән бәйләнеп чыгып китте. Ул чыгып качты дип тынычлык килмәде. Мине бик зур проблемалар, түләп булмаслык әҗәтләр белән калдырды. Ул еллардагы авырлыкларымны сөйләп бетерерлек түгел. Кызым белән икәү калдык, баламның үсмер чоры иде. Иремнең әҗәтләрен түләр өчен 15 гектар җир алып, анда кишер чәчеп, ике ел бизнес белән дә шөгыльләнеп алдым. Шөкер, булышучы булды. Мин дә, үз ягымнан булдыра алганча, бурычымны кайтарырга тырыштым.

Зимфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА.

Әңгәмәне тулысынча www.shahrikazan.com сайтында укыгыз

Узышлар узды, чаңгы калды

СПОРТ

Казанда 18 февральдә «Россия чаңгы юллары – 2017» чаңгыда массакүләм узышларында 20 меңнән артык кеше катнашты.

Дамир БӘДРИЕВ

Автор фотосы

Юдино бистәсендәге «Локомотив» стадионында республика премьер-министры урынбасары Васыйл Шәйхразиев казанлыларны Татарстан Президенты исеменнән спорт бәйрәме белән котлады. Республикада 11 февральдә «Россия чаңгы юллары» шигаре астында үткәрелгән узышларда 170 мең кеше катнашканлыгын әйтеп үтте ул.

– Башкалада узган шимбәдә 20 меңнән артык кеше стартка басты. Иң өлкән чаңгычы Петр Яльдиряковка – 91, ә иң яшь Есения Дуженковага биш кенә яшь иде, – дип хәбәр итте шәһәр башкарма комитетының физкультура һәм спорт комитеты җитәкчесе Светлана Вострикова кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Казанда 3-10 километрга узышларда Арина Лисина, Илья Куницын, Артем Николаев, Елена Горохова беренчелеккә ирештеләр. VIP узышларда Татарстан вәкилләреннән ир-атлар арасында 2017 метрга узышта җиңүне Министрлар кабинетының аппарат җитәкчесе урынбасары – эшләр идарәчесе Сергей Коростылев яулады. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе җитәкчесе Ленар Габдерахманов – икенче, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Рифкать Миңнеханов өченче булды. Хатын-кызлар арасында мәдәният институты проректоры Роза Әхмәдиевага тиңнәр табылмады. Икенче – «Мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль фонды» дәүләт учреждениесе директоры Алсу Мифтахова, өченче – Татарстан Президенты аппаратының бүлек җитәкчесе Резеда Сабирова.

Казан җитәкчеләре арасында беренче – энергоуниверситет ректоры Эдвард Абдуллаҗанов. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Дамир Фәттахов – икенче, ә медицина университеты ректоры Алексей Созинов өченче булып финишка килде. Хатын-кызлардан шәһәр башкарма комитетының туристлыкны үстерүгә теләктәшлек комитеты рәисе Дарья Санникова иң яхшы күрсәткечкә иреште.

Башкала мэры Илсур Метшин, чаңгы узышлары тәмамланса да, чаңгыларны онытмаска чакырды.

– Киров районындагы 3нче гимназия янында модульле чаңгы базасы төзeләчәк. «Локомотив» стадионында чаңгы трассасы ясалачак, – диде Илсур Метшин.

Көчле рухлылар чемпионаты

Алар сүзгә саран. Үзләренә кызганып караганны яратмый. Хәер, инвалид коляскасында булсалар да, гадәттә, кешеләр аларга кызганып түгел, сокланып карый. Тормышка теше-тырнагы белән шулкадәр ябышып яшәүчеләр сәламәт кешеләр арасында да сирәк очрый бит. Сүзем инвалид коляскасындагы баскетболчылар турында бара.

Алисә САБИРОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

18-21 февраль көннәрендә республикада 120гә якын спортчы Россия чемпионы исеме өчен көрәшә. Татарстанда мондый төр ярыш әле беренче тапкыр уза. Чемпионат мөмкинлекләре чикле спортчылар өчен уңайлы булган Васильево бистәсендәге (Яшел Үзән районы) «УНИКС» кунакханә-спорт комплексы бинасында бара. Бу – Россиядә иң яхшы базаларның берсе. Якын киләчәктә ул баскетбол буенча паралимпия уеннарына әзерлек урыны булып торачак.

– Хәзерге вакытта бу хакта сөйләшүләр алып барабыз. Биредә бөтен нәрсә дә бер түбә астында: спорт залы да, кунакханәсе дә, ял бүлмәләре дә бар. Ярышлардан соң кешеләр, юынып, номерларына менә ала. Мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен бу аеруча кирәкле шартлар, – диде Татарстанның инвалидлар җәмгыяте рәисе Рифат Ганибаев.

Ярышларда Татарстаннан «Барс канатлары» һәм «Чаллы» командалары көч сынашты. Шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург, Төмән, Ульяновск, Ижау шәһәрләреннән килгән спортчылар да бар. «Барс канатлары» Казан командасы беренче көнне үк «Локомотив» (Ижау) белән уенда җиңү яулады. «Барслар» сүзләренчә, бу – иң җиңел уеннарның берсе.

– «Локомотив» әле яңа команда, шуңа да аларны көндәшләр дип әйтә алмыйбыз. Алдан да кече турнирда очрашкан бар, аларның алымнары белән яхшы таныш без, – диде баскетболчы Динар Камалиев.

Спортчылар өчен бу чемпионат – мөһим турнирларның берсе, чөнки ярышлар барышын Россия җыелма командасы тренерлары күзәтә. Димәк, турыдан-туры ил җыелмасына эләгергә мөмкин. Шулай ук турнир – спорт мастеры исемен алу өчен дә зур мөмкинлек.

Санкт-Петербургның «БасКИ» командасыннан тыш, Мәскәүнең «Фалькон»ы да – безнекеләрнең төп көндәшләре. Соңгысы – тәҗрибәле командаларның берсе.

– Баскетболга кереп китүе авыр түгел, ләкин бер «капсаң», тиз генә котыла алмыйсың, – дип елмая «Фалькон» спортчысы Александр Карасюк. – Без – 90нчы еллардан формалашкан команда, ләкин әле беребезне дә профессионал дип әйтә алмыйбыз. Яхшы уенчылар гына без. Ә профессионал булу өчен бер генә гомер житми. Көн саен боҗрага туп ату, тактика, физик халәтне ныгыту буенча күнекмәләр ясыйбыз. Бер кеше дә безне монда мәҗбүриләп алып килмәде. Ярышларда катнашкан өчен дә берәү дә акча түләми. Дәрес, автобус һәм спортзалны бушка бирәләр. Үз-үзебезне тәэмин итү өчен башка чаралар эзлибез. Ләкин баскетболсыз инде яши алмыйбыз, бу – безнең мәхәббәт, – диде ул.

Башкалалардан аермалы буларак, республикабыз коляскадагы баскетболчыларга акчалата ярдәм итә. Безнекеләр өчен бу хобби гына түгел, ә кәсепнең бер төре дә әле. Финалда «Барс канатлары» төп көндәшләре «БасКИ» белән очрашачак. Өч ел рәттән икенче урында барган «барслар» быел беренчелеккә чыкмакчы. Бу турнирдан соң алар Бөекбританиянең Шеффилд шәһәрендә узачак Еврокубок ярышларына җыена.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

Бу санның тиражы – 1545. Гомуми тираж – 6219.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 679. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы